ГЛАВА ЧУКМАРЛИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САРМАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САРМАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЧУКМАРЛЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**2025ел, 7 ноябрь** **№ 4**

Сарман муниципаль районы Чукмарлы авыл җирлегенең Чукмарлы авылында 2026 елда үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Иҗтимагый хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Сарман муниципаль районының Чукмарлы авыл җирлеге Уставының 18.1 маддәсенә таянып, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы «Чукмарлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы карар кабул итте:

1. 2026 елның 19 ноябрендә 10.00 сәгатькә Сарман муниципаль районы Чукмарлы авылы, Совет урамы, 41 нче йорт адресы буенча урнашкан Чукмарлы авыл җирлегендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
«Сез 2026 елда яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 600 сум күләмендә үзара салым кертүгә ризамы? Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Чукмарлы авыл җирлегенең Чукмарлы авыл җирлегендә, I төркем инвалидлардан, хәрби хезмәт үтүче гражданнардан, көндезге булектэ белем алучы студентлардан тыш, хәрби хезмәт, махсус хәрби операциядә катнашучылардан алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп баручы, түбәндәге эшләрне башкару буенча:

1) тышкы яктырту урам челтәрләрен, трансформаторларны һәм алар астындагы башка подстанцияләрне һәм мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау Чукмарлы торак пунктында (лампалар, энергия саклаучы яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен килешү буенча түләү)
2) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Чукмарлы торак

пунктында кышкы чорда территорияне кардан җыештыру, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү )
3) Чукмарлы авылы торак пункты территориясен төзекләндерү (роторлы чапкыч, триммер сатып алу, җәйге вакытта территорияне чабу (Чукмарлы торак пунктында килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү, Беларусь МТЗ 82 тракторы өчен ягулык-майлау материаллары сатып алу, газон чапкыч өчен ягулык-майлау материаллары сатып алу Беларусь МТЗ 82 тракторы өчен запас частьләр сатып алу), килешү буенча хезмәтләр өчен түләү, кар чистарту машинасы, эскәмияләр әзерләү өчен төзелеш материаллары сатып алу.

“ЭЙЕ” “КАРШЫ".

3. «Сарман муниципаль районының Чукмарлы авыл җирлеге башлыгы карары «2026 елда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Сарман муниципаль районының Чукмарлы авыл җирлегендә гражданнар җыенын билгеләү турында» 01.11.2025елдагы 2 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарны 7 көн эчендә «Сарман муниципаль районы» , муниципаль берэмлекнен рэсми сайтына, «Интернет мәгълүмат» теле коммуникация челтэрендэ, Чукмарлы жирлеге стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә,
5. Әлеге карар игълан ителгэн көннән үз көченә керә.

Чукмарлы авыл җирлеге башлыгы
Сарман муниципаль районы: И.Н. Хадиуллин